**Рус телендә гомуми урта белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендә белем алучы 10 нчы сыйныф укучыларына татар әдәбиятыннан муниципаль тур өчен олимпиада сорауларына җаваплар**

Максималь балл – **45**

**1. Әдәбияттагы нинди юнәлеш турында сүз баруын языгыз (2 балл):**

- аның асылын Урта гасыр мөселман дөньясында киң таралган тәгълимат тәшкил итә;
- аның тарафдарларын башка төрле итеп «диндар», «дәрвиш», «тәкъва», «акыл иясе» дип йөрткәннәр;
- әдәбияттагы әлеге күренеш мөселман кешесенең үз-үзен, рухын камилләштерү юлы белән Аллага якынаюын һәм кушылуын күздә тоткан төрле системадагы дини-фәлсәфи, мистик карашлар һәм йолалар җыелмасыннан гыйбарәт.

**Җавап:** суфичылык әдәбияты

**2. Хата белән бирелгән төшенчәләр рәтен күрсәтеп языгыз (2 балл):**

а) мәрсия, мәдхия, бәет, газәл

ә) йола һәм уен-бию җырлары, тарихи җырлар, лирик озын җырлар, кыска җырлар

б) сюжетлы шигырь, поэма, баллада, нәсер

**Җавап:** а) мәрсия, мәдхия, бәет, газәл

**3. Әдипләр портретларын һәм әсәрләргә рәсем-иллюстрацияләрне карагыз.**

**а) Язучыларны һәм аларның әсәрләренә ясалган рәсемнәрне туры китереп билгеләгез (3 балл):**

1) 2) 3)





а) ә) б)





______________________________________________

**Җавап:** 1) ә; 2) б; 3) а.

**ә) Әсәрләрнең авторларын һәм исемнәрен языгыз (3 балл):**

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

**Җавап:**

Кол Гали «Кыйссаи Йосыф»

Габдрахман Әпсәләмов «Ак чәчәкләр»

Әмирхан Еники «Әйтелмәгән васыять»

**ә) Шул әсәрләрнең берсе турында белгәннәрегезне языгыз (5 балл).**

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

______________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

**4. Персонажларны кайсы әсәрдән алынганлыгын билгеләгез (4 балл):**

| | |
|---|---|
| 1) Мансур | а) «Әйтелмәгән васыять» |
| 2) Суфиян | ә) «Галиябану» |
| 3) Исмәгыйль | б) «Кыйссаи Йосыф» |
| 4) Йагъкуб | в) «Ак чәчәкләр» |

**Җавап:** 1) в; 2) а); 3) ә; 4) б.

**5. Шигырьдән өзекне укыгыз. Сорауларга җавап языгыз.**

... Әнә шул өй эчендә ястүеннән соңра бер карчык
Намазлыкка утырган, бар җиһаннан күңлене арчып;

Күтәргән кул догага, яд итә (исенә төшерә) ул шунда үз угълын:
Ходаем, ди, бәхетле булсайде сөйгән, газиз угълым!

Тамадыр мескинәмнең тамчы-тамчы күзләреннән яшь;
Карагыз: шул догамы инде Тәңре каршына бармас?

**а) Әсәрнең исеме (1 балл)**___________

**ә) Әсәрнең авторы (1 балл)**__________

**б) Исегезгә төшерегез: шигырьнең беренче өлешендә нәрсә күренеше бирелә? (3 балл)**______________________________________________

__________________________________________________________________

__________________________________________________________________

**в) Ана теләгенең көчен шигырьдә кайсы детальләр белдерә, шуларны язып чыгыгыз (3 балл)**________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

**г) Әлеге шигыре белән автор нәрсә әйтергә теләгән? Әсәрнең идеясен билгеләп языгыз (3 балл)** ____________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

**Җаваплар:**

а) Ана догасы

ә) Габдулла Тукай

б) Шигырьнең беренче өлешендә төнге авыл күренеше бирелә.

в) Догага күтәрелгән куллар, улына Ходайдан бәхет сорау, тамчы-тамчы күз яшьләре.

г) Барлык аналар үз балаларына яхшылык, балаларының бәхетле булуын тели.

**6. Терәк сүзләрдән файдаланып, зур булмаган инша языгыз (15 балл).**

*Кәләш, кияү, йола, туй, никах, мәҗлес, ак бөркәнчек, бал-май, хөрмәт итү, мәхәббәт хисе, бәхет теләү, әти-әни, туганнар.*

**Иншгызның текстында әлеге сүзләрнең сайланышы ирекле.**

**Татар әдәбиятыннан мисаллар китерергә онытмагыз.**

**Иншагызга кыска һәм мәгънәле исем бирегез. Иншаның күләме – 8-10 җөмлә.**

.